**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 с. Нармонка,
ул. Молодежная , д.12 а
тел: 4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НАРМОНКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕН БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ**
422630 Нармонка авылы,
Яшьләр урамы, 12 а нчы йорт,
тел: 4-62-24

---

**2024 елның 15 июле** **10 номер**

# КАРАР

## Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерүгә җаваплы зат итеп билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерүгә вәкаләтләр бирү турында» 2009 елның 25 августындагы 1556 номерлы карары нигезендә:

1. Нармонка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе **Мөбәрәкшин Илшат Фәиз улын** дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен җаваплы зат итеп билгеләргә һәм вәкаләт бирергә.

2. «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре чикләрен килештерү өчен җаваплы зат итеп билгеләү турында» Нармонка авыл җирлегенең 2023 елның 21 мартындагы 8 номерлы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерүгә вәкаләтле җаваплы зат тарафыннан сишәмбе Нармонка авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында 8 сәгатьтән 12 сәгатькә кадәр гражданнарны кабул итү графигын һәм вакытын расларга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Нармонка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Ф. Мөбәрәкшин**